| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУТЛУ-БУКАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КОТЛЫ-БӨКӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|
| 422665, с. Кутлу-Букаш, ул. Советская, дом 32 | 422665, Котлы-Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 нче йорт, |

Тел.: (84361) 31521, факс: (84361) 31642, Kbuk.Rs@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 27 марты** **Котлы Бөкәш авылы** **№ 10**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең 2017 елның 16 ноябрендәге 32 номерлы карары белән расланган 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының « Котлы Бөкәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең 2017-2035 елларга социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башкарма комитетының 16.11.2017 ел, № 32 карары белән расланган 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.4 пунктның өченче абзацында.:

«муниципаль заказны формалаштыру» сүзләрен «муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

«максатчан программалар» сүзләрен «муниципаль программалар» сүзләренә алмаштырырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы 34 йорт; Мәмли Казак Чаллысы авылы, Үзәк урам 29 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Г.Г.Нәҗипов
Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башлыгы